ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 17 » декабрь 2019 ел** **№ 1108**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Иске Ашыт төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы - «Иске Кенәр башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» эшчәнлеген туктатып тору турында**

Оптимальләштерү процедураларын уздыруга һәм матди-техник, кадрлар, идарә ресурсларын нәтиҗәле файдалану, мәгариф учреждениеләренең финанс чыгымнарын оптимальләштерү максатыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Иске Ашыт төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы - «Иске Кенәр башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» эшчәнлеген туктатып торырга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенә (Р.Д. Мөхәмәдияров):

-алга таба Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Иске Ашыт төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе филиалы - «Иске Кенәр башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» укучыларын алга таба укытуга бәйле оештыру чараларын үткәрергә;

- эштән азат ителгән хезмәткәрләрне хезмәт законнарына ярашлы рәвештш эшкә урнаштыру мәсьәләләрен хәл итәргә;

- муниципаль филиал бинасын һәм мөлкәтен саклау өчен җаваплылыкны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Иске Ашыт төп гомуми белем бирү мәктәбе» бюджет гомуми белем бирү учреждениесе - «Иске Кенәр башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» мәктәп директоры А.В. Мостафинга йөкләргә.

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә (Ф.Р. Исмәгыйлев), «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесенә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Иске Ашыт төп гомуми белем бирү мәктәбе»

муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең штат расписаниесенә тиешле үзгәрешләр кертергә.

4. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http//arsk/tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин